# Фәнис Яруллин.
# « Әхмәт» хикәясе

# Әхмәт әнисе белән генә яши.



Анның әнисе бик күп эшли: кер юа, тәмле ашлар пешерә ,өй җыештыра, су алып кайта.


Reklama
com.ua











# Әхмәт урамда уйный,энисенә бик аз булыша





Кызганычка каршы , беркөнне анын әнисе нык авырды, урыныннан тормады.



Ул Әхмәтне янына чакырды да:

- Улым, чишмәдән су алып кайт әле, салкын чишмә суы эчсәм, терелермен кебек,- диде.



Әхмәт суны урамдагы коедан гына алып кайтты.



Әнисе суны эчте дә: «Рәхмәт , улым. Ләкин бүген су нигәдер салкын да, тәмле дә түгел»,-диде.
Әхмәт кып-кызыл булды, елап җибәрде.



Тәрҗемә итегез.

Чишмә суы-
ерактагы чишмә**ДӘН**-
аз булыша-
нык авырды-
үз янына чакырды-
бик эссе-
урамдагы кое**ДАН**-
елап җибәрде-

Сорауларга җавап бир.

1.Әхмәт кем белән яши?
2.Алар кайда яшиләр?
3.Әнисе өйдә нинди эшләр эшли?
4.Әхмәт аңа булышамы?
5.Беркөнне кем авырды?
6.Әнисе аңа нәрсә диде?
7.Әхмәт суны кайдан алды?
8.Әнисенә рәхәт булдымы? Ни өчен?
9.Нигә Әхмәт елап җибәрде?
10.Синеңчә,Әхмәт нинди малай?

# Тәрҗемә итегез.

Эшчән-
Тырыш-
ялкау-
әдәпле-
эш яратмый-
уйнарга ярата-
тәрбиясез-
тыйнак-
алдакчы-
ихтирамлы-

Җөмләләрне үрнәк буенча дәвам итегез.

Минемчә, Әхмәт эш яратмый, чөнки ул әнисенә бик аз булыша.

Минем уйлавымча, …..

Минем фикеремчә,…..

Әлбәттә,…

Бәхеткә каршы,…

Кызганычка каршы,….